# ГРАЖДАННАР ҖЫЕНЫ КАРАРЫ

Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы Сон авыл җирлеге составына керүче Кече Сон торак пунктында 2021 елга үзара салым кертү турында

№ 3 13 ноябрь 2020 ел

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында»гы 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ санлы Федераль законның 25.1, 56 нчы статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында»гы 2004 елның 28 июлендәге 45-ЗРТ санлы Татарстан Республикасы законының 35 нче статьясы, «Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы Сон авыл җирлеге муниципаль берәмлеге» Уставының 23 статьясы нигезендә Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы Сон авыл җирлегенең Кече Сон торак пунктында узган гражданнар җыены

КАРАР КАБУЛ ИТТЕ:

1. Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы Сон авыл җирлеге Кече Сон торак пункты территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән балигъ булган гражданнарга, 1 һәм 2 группа инвалидлар, Бөек Ватан сугышы һәм хәрби хәрәкәтләрдә катнашкан ветераннар, Бөек Ватан сугышында һәм хәрби хәрәкәтләрдә катнашканнарның тол хатыннары, күп балалы гаиләләр, көндезге бүлектә белем алучы студентлар, Россия Армиясе сафларында хезмәт итүчеләрдән кала, 2021 елда 1000 (Бер мең) сум күләмендә үзара салым кертергә.

2. Җыелган акчаларны җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итү буенча түбәндәге эшләрне башкаруга тотарга:

- Кече Сон торак пунктында Гагарин урамына вак таш, ком җәю (алып кайту, җәю, килешү буенча түләү);
- Кече Сон торак пунктында мәчет янына вак таш, ком җәю (алып кайту, җәю, килешү буенча түләү);
- Кече Сон торак пунктында “Сугыш чоры балаларына” монумент урнаштыру, тротуар җәю, скверны коймa белән әйләндереп алу (материаллар алып кайту, килешү буенча түләү);
- Кече Сон торак пунктында, урамнарны яктырту өчен, энергия саклаучы лампалар сатып алу, урнаштыру:
- Кече Сон торак пунктындагы юлларны тигезләү һәм кардан чистарту.

3. Әлеге карарны Сон авыл җирлегенең мәгълүмат стендларында, Мамадыш муниципаль районы mamadysh.tatarstan.ru сайтында, Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында (pravo.tatarstan.ru.) урнаштыру юлы белән халыкка җиткерергә.

Гражданнар җыенында рәислек итүче,
Мамадыш муниципаль районы
Сон авыл җирлеге Башлыгы,
Совет рәисе М.Ф.Сәләхов